БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
15 декабрь 2022 ел

**КАРАР**
№ 156

**«2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2021 елның 20 декабрендәге 91 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. «2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2021 елның 20 декабрендәге 91 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2022 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 1180869,94 мең сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 1227322,95 мең сум итеп;

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын 46453,01 мең сум итеп».

1.2. Карарның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны түбәндәгечә исәпкә алырга:

- әлеге карарның 15 нче кушымтасы нигезендә 2022 елда 832211,47 мең сум итеп;

- әлеге карарның 16 нче кушымтасы нигезендә 2023 елда 693628,02 мең сум һәм 2024 елда 671192,22 мең сум итеп.»

1.3. Карарның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2022 елга 19133,67 мең сум, 2023 елга 17500,00 мең

сум, 2024 елга 17600,00 мең сум итеп расларга һәм аларны тиешенчә 2022, 2023 һәм 2024 елларда Балтач муниципаль районының гомуми файдалану юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.».

1.4. Әлеге карарның 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче, 6 нчы, кушымталары нигезендә «2022 елга һәм 2023-2024 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2021 елның 20 декабрендәге 91 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарының 1 нче, 3 нче, 5нче, 7 нче, 15 нче, 17 нче кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин